КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 март г.Казань № 162

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 31 август, 746 нчы; 2013 ел, 14 март, 160 нчы; 2013 ел, 29 август, 611 нче; 2014 ел, 28 март, 194 нче; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2015 ел, 21 октябрь, 789 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1001 нче; 2016 ел, 7 октябрь, 725 нче; 2017 ел, 15 август, 581 нче; 2017 ел, 7 декабрь, 953 нче; 2018 ел, 31 май, 411 нче; 2019 ел, 15 гыйнвар, 4 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 нче пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән – мәгълүматлаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15);»;

3.3 нче пунктта:

$3.3.1^{1}$ нче пунктчада:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урманнарны урман-парк зоналарында урнашкан урманнарга, яшел зоналарда урнашкан урманнарга кертү турында; урманнар урнашкан урман-парк зоналарында функциональ зоналарны билгеләү, Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясындагы 1 өлешнең 3 һәм 4 нче пунктларында күрсәтелгән урманнар урнашкан җирләрнең мәйданын һәм чикләрен билгеләү һәм үзгәртү буенча; урман

фонды җирләре чикләрендә урнашкан урман кишәрлекләренә карата ачык сервитутларны билгеләү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«урман-парк яшел поясы чикләрен билгеләүне һәм үзгәртүне гамәлгә ашыра.»;

3.3.7 нче пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контролен гамәлгә ашыра.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2007 ел, 5 март, 74 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 18 июнь, 246 нчы; 2009 ел, 19 гыйнвар, 24 нче; 2010 ел, 27 июль, 591 нче; 2012 ел, 2 февраль, 78 нче; 2013 ел, 31 август, 622 нче; 2014 ел, 23 декабрь, 1006 нчы; 2015 ел, 26 сентябрь, 711 нче; 2015 ел, 21 октябрь, 789 нчы; 2015 ел, 24 декабрь, 970 нче; 2018 ел, 26 ноябрь, 1058 нче; 2019 ел, 17 август, 686 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы коллегиясе (алга таба – коллегия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

коллегия составыннан А.С.Пуряевны чыгарырга;

коллегия составына «Көнчыгыш Европа урман тәҗрибә станциясе» Бөтенроссия урманчылык һәм урман хуҗалыгын механикалаштыру фәнни-тикшеренү институты» федераль бюджет учреждениесе филиалы директоры вазыйфаларын башкаручы Федор Степанович Ильинны (килешү буенча) кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин